**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 май 2023 № 395

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының «Милек буларак арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021елның 21 июлендәге 217 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында.**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 29 декабрендагы 605-ФЗ номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының «Милек буларак арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 21.07.2021 № 217 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. преамбуласындагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары» сүзләрен «”Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчен югалтуын тану турында” 28.02.2022 № 175 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары» сүзләре белән алмаштырырга;

1.2. Административ регламентның 2.9.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.9.2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан мондый милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алынган арендага алынган милек өчен түләү бер тапкыр яки рассрочка белән ай саен яки квартал саен тигез өлешләрдә түләүләр аша башкарыла.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитеты житәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Каюмов